**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«11» 01 2022 Яр Чаллы шәһәре № 2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлегенең 16:39:030302:348 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 29 марттагы 31/7 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районының Князево авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, район уставы, «Якты юл» («Светлый путь») газетасында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган 2021 елның 4 августындагы халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлегенең 16:39:030302:348 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән (Магазиннар) «Шәхси торак төзелеше өчен» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртергә.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары О.А. Никитинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин